| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2 августа 2016 г.** | Зеленодольск ш. | **КАРАР**<br>**№ 1991** |
| --- | --- | --- |

2016 елда Зеленодольск муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыеп алуда комбайнчылар арасында алдынгыларны билгеләү тәртибен раслау турында

«2013-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» максатчан программасы нигезендә, урып-җыю эшләрен вакытында башкару һәм ашлык җыю комбайнчылары арасында башкарылган эшләр (ашлык суктыру) өчен алдынгыларны билгеләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 елда Зеленодольск муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыюда ярышлар уздыру һәм ашлык җыю комбайнчылары арасында алдынгы хезмәткәрләрне билгеләү буенча комиссия төзү турындагы нигезләмәне № 1 кушымта нигезендә расларга.
2. 2 нче кушымта нигезендә 2016 елда Зеленодольск муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыеп алуда ашлык җыю комбайнчыларының алдынгыларын билгеләү буенча комиссия составын расларга.
3. Әлеге карарны "Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернетта урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин

2016 елның 2 нче
августындагы1991номерлы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә 2016 елда бөртекле һәм кузаклы культуралар уңышын җыеп алуда ярышлар уздыру һәм бөртекле-кузаклы культуралар комбайнчылары арасында алдынгы хезмәткәрләрне билгеләү буенча комиссия төзү турында НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми өлеш.

1.1. Әлеге нигезләмә «2013-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районының авыл хуҗалыгын үстерү» максатчан программасын гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән, төркемнәр буенча башкарылган эшләр (ашлык суктыру) күләмен премияләү максатларында, комбайнчылар арасында ашлык җыю алдынгыларын билгеләү тәртибен билгели:

1 Төркем –«Тукано», «Нью-Холланд», «Мега-360,370», «Лекион», «Мега-204»комбайннары;

2 төркем - «Акрос», «Торум», «ДОН-1500»комбайннары;

3 төркем – СК-5 комбайннары, Ениисей.

1.2. Чараны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-ЗМР башкарма комитеты) һәм ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе оештыра.

1.3. Финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджеты хисабына башкарыла.

1.4. Ашлык җыю комбайнчылары алдынгыларының эшенә йомгак ясау 2016 елның 1 августыннан 31 сентябренә кадәр уздырыла.

2. Максатлар һәм бурычлар.

2.1. Ашлык җыю эшләренең сыйфатын һәм агротехник срокларда ашлык җыю күләмен арттыруда, шулай ук хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә, технологик процессларны башкаруда, куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен үтәүдә һәм хезмәтне саклау шартларын яхшыртуда ашлык җыю комбайнчылары арасында кызыксынуны арттыру.

3. Комиссиянең эш тәртибе.

3.1. Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренең ашлык җыю комбайнчылары арасында алдынгы хезмәткәрләрне билгеләү буенча комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең әлеге

карары белән төзелә.

3.2. Комиссия авыл хуҗалыгы предприятиеләреннән һәм КФХЛАРДАН алдынгы хезмәткәрләрнең эш нәтиҗәләре турында мәгълүмат ала, мәгълүматларны өйрәнә һәм 20 көнгә бер тапкыр алдынгы хезмәткәрләрне билгели.

3.3. Комиссия утырышларын комиссия рәисе үткәрә.

3.4. Ашлык җыю комбайнчылары арасында алдынгыларны билгеләү әлеге Нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән номинацияләр буенча шартлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5. Йомгаклау комиссия тарафыннан хисап чорыннан соң 10 көн эчендә үткәрелә. Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3.6. Эш башкару комиссия секретаренә йөкләнгән.

## 4. Акча түләү тәртибе.

4.1. Комиссия утырышының әзерләнгән беркетмәсе номинацияләр буенча җиңүчеләр белән ЗМР Башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлегенә җибәрелә.

4.2. Бюджет ассигнованиеләре бүлеп биргәннән һәм документларның тулы пакетын биргәннән соң 15 көн дәвамында (комиссия утырышы беркетмәсе, паспорт белешмәләре, ИНН, иминият таныклыгы, Россия Саклык банкының шәхси счетыннан өземтә) Россия Саклык банкында ачылган шәхси счетларга номинацияләр буенча җиңүчеләргә акчалата түләүләр күчерә.

4.3. Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән акчалата түләүләр бирү нәтиҗәләре буенча аларның күләменең дөрес һәм нигезле булуына тикшерүләр үткәрә.

## 5. Эш нәтиҗәләре буенча матди стимуллаштыру чаралары.

Матди стимуллаштыру чаралары номинацияләр буенча билгеләргә.

5.1. Барлык төркемнәр буенча ашлык җыю комбайнчыларының акчалата бүләкләү күләмен билгеләү:

1 урын өчен-4000 сум.;

2 урын өчен-3000 сум.;

3 урын өчен-2000 сум.

5.1.1. Ашлык җыю комбайнчылары арасында алдынгыларны билгеләү өчен күрсәткечләрне кулланырга:

а) 20 көн эчендә билгеле маркалы комбайнчы ашлыкны иң күп суктырган;

б) сыйфатлы, агротехник срокларда, ашлык җыю эшләрен башкару;

в) хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, технологик процессларны үтәү;

г) куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен үтәү.

## 6. Алдынгыларны билгеләү өчен мәгълүмат бирү тәртибе.

6.1. Районның авыл хуҗалыгы формированиеләре һәм КФХлар көн саен җитәкче имзасы һәм мөһере белән Зеленодольск муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә расланган алдынгылар исемлеген тапшыралар.

6.2. Авыл хуҗалыгы формированиеләре һәм КФХ җитәкчеләре алдынгыларны билгеләү өчен ышанычлы мәгълүмат бирергә тиеш. Дөрес булмаган мәгълүмат бирелгән очракта, җитәкчеләр гамәлдәге законнар нигезендә шәхси җаваплылыкка тартыла.

2016 елның 2 нче августындагы1991номерлы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
2 нче кушымта

**2016 елда бөртекле культуралар җыюда Зеленодольск муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең ашлык җыю комбайнчылары алдынгыларын билгеләү буенча**
**Комиссия составы**

**Комиссия рәисе**

| | |
|---|---|
| Сахибуллин Айрат Хадисович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе. |

**Комиссия сәркатибе:**

| | |
|---|---|
| Галлова Елена Петровна | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге консультанты (килештерү буенча). |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Кадырова Светлана Викторовна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Зиганшин Тагир Галимзянович | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зеленодольск муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килештерү буенча); |
| Хайретдинов Наиль Киямович | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең план-маркетинг бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Шарипов Шаукат Шамильевич | Зеленодольск муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең игенчелек буенча консультанты (килештерү буенча). |